ГЛАВА
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район
422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы ,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

22.09.2018 № 28

Җирле референдум уздыру инициативасы турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003елның 06 июнендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 маддәсе, 56 маддәсе, “Җирле референдум турында” 2014 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, “Җирле референдум турында” 2014 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23-ТРЗ маддәсе, Яңа Борындык авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 декабрендәге 909 номерлы карары нигезендә гражданнарның үзара салымын җәлеп итеп, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында” (үзгәрешләр белән 14.01.2014г. №3, 12.02.2015г. №85, 03.10.2016г. №706):

1. Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә җирле референдум уздыруның уртак инициативасын сорау буенча чыгарырга:

«Чүпрәле муниципаль районының Яңа Борындык авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2019 елда үзара салым акчаларын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерүгә сез риза микән:

- Мәктәп, Гагарин урамнары буйлап вак таш юл салу Борындык поселогонда
- Борындык бистәсендәге зиратка илтә торган юлны карап тоту һәм ремонтлау

"ӘЙЕ" "ЮК".

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталының Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Яңа Борындык авыл
җирлеге башлыгы В.Г. Ранцев